ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 07.02.2025 285 **КАРАР**

Аерым категория гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы, Алабуга муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 47 статьясы, Алабуга муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында» 2020 елның 17 августындагы 491 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 27 июлендәге 935 номерлы карары белән расланган махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 1 бүлеген түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга:

«01.01.2025 елдан 31.12.2025 елга кадәр - 300 000,0 (өч йөз мең) сум.»;

1.2. Тәртипнең 2.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү 2024 елның 4 мартыннан 2025 елның 31 декабренә кадәрге чорда контракт төзегән гражданнарга бирелә.

1.3. Тәртипнең 3.2. пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024 елның 4 мартыннан 2025 елның 31 декабренә кадәрге чорда махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданы (контрактчы) имгәнү (яралану, травма, контузия) нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) очракта, ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән зат әлеге Тәртипнең

3.2. нче пунктында күрсәтелгән адресына теркәлгән документлар белән бергә, әлеге Тәртипкә 1.1. нче кушымта итеп бирелгән форма нигезендә гариза җибәрә.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева